**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

# КАРАР

№ 33 11.03.2016ел .

Аксубай муниципаль районы Советының «өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре исемлеген билгеләү тәртибе турында»09.08.2012 ел, № 118 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең 25.10.2001 елгы 136-ФЗ номерлы Җир кодексына, 23.06.2014 елгы 171-ФЗ номерлы Федераль законына ярашлы "Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына , «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 25.10.2001 ел, № 137-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында шәһәр, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән идарә итү буенча вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 26.12.2015 ел, №108-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы белән «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән идарә итү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 26.12.2015 №109-ТРЗ Татарстан Республикасы законы белән Аксубай муниципаль районы Советы карар кылды:

1. Аксубай муниципаль районы Советының 09.08.2012 ел, № 118 карары белән расланган Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре исемлеген билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. Өч һәм аннан да күбрәк балалы гражданнарга җир кишәрлекләре исемлеген билгеләү тартибәнең 2 пунктлары түбәндәгәя редакциясе бәян ителергәй тиеш::

2. Әлеге Тәртип нигезендә өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарга түләүсез бирелә торган җир кишәрлекләре исемлеге (алга таба – исемлек) Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан билгеләнә».

2.Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://aksubayevo.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Советының агросәнәгать комплексы, җирдән файдалану һәм экология мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
Совет Рәисе К. К. Гилманов